Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Урманай авылы №10/94 28 апрель 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 37/108 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында(29.10.2015 елның 13/13 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 30 сентябрендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Урманай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 37/108 номерлы карарына (2015 елның 29 октябрендәге 13/13 номерлы карар редакциясендә), 2 пунктның 3 пунктчасының дүртенче абзацындагы үзгәрешне «бер торак бина (Торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт»сүзләренә алыштырып кертергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен кертә.

3. Әлеге карарны район «Маяк» газетасында бастырырга һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatarstan.ru.веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, Финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.И.Закиров